Кукмара муниципаль районы
Починок-Кучук авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«26» март, 2024 ел № 7

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок-Кучук торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок-Кучук торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы Починок-Кучук авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Починок-Кучук авыл җирлеге Уставы нигезендә Починок-Кучук авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 7 апрелендә 08 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок-Кучук торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы Починок-Кучук авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Кучук авылы, Мәктәп урамы, 47 адресында урнашкан Починок-Кучук авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 7 апрелендә 09 сәгать 30 минутка «Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок Кучук торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы Починок Кучук авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Кучук авылы, Мәктәп урамы, 47 адресында урнашкан Починок-Кучук авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 7 апрелендә 11 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок Кучук торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы Починок Кучук авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча

гражданнар жыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар жыенын Починок Кучук авылы, Мәктәп урамы, 47 адресында урнашкан Починок-Кучук авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

4. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

**«Сез Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Починок-Кучук авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:** «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Починок-Кучук авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 5200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр;
- су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;
- территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре;
- янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Починок-Кучук авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- гидротехник корылмаларны (Синерь буасын) ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасына гидротехник корылмаларга (Синерь буасына) керү өчен мәйданчыкны төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техик күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, гидротехник корылмаларны ремонтлау, төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- мемориаль корылмалар (һәйкәл, обелиск, мемориаль тактала) сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, мемориаль корылмаларны сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;
- массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре;

- Починок-Кучук авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре,

**2023 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:**

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Починок-Кучук авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета

документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау (гидротехник корылмаларны (Синерь буасын) ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасына гидротехник корылмаларга (Синерь буасына) керү өчен мәйданчыкны төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техик күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, гидротехник корылмаларны ремонтлау, төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (мемориаль корыямалар (һәйкәл, обелиск, мемориаль такталар) сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, мемориаль корылмаларны сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү,

массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре),

(хәрби-патриотик чаралар өчен хәрби костюмнар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Починок-Кучук авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Починок-Кучук авыл җирлеге
башлыгы: Гиниятов Р.А.